ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАЙРЯКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ ЮТАЗИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Ютазинская, д.14А,
с.Байряка, 423963

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БӘЙРӘКӘ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
Ютазы урамы, 14А йорты,
Бәйрәкә авылы, 423963

Тел.:(85593) 2-44-12, факс:2-44-13, e-mail: Bay.Utz@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

№11 7 сентябрь 2023 ел

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкә авыл җирлеге Башкарма комитетының 2012 елның 2 ноябрендәге 23 санлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкә авыл җирлеге башкарма комитетында гражданнарның һәм юридик затларның мөрәҗәгатьләрен карау буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль закон, 2006 елның 02 маендагы «Россия Федерациясе гражданнарының мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында»гы 59-ФЗ санлы Федераль закон, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында»гы федераль закон, 2023 елның 26 гыйнварындагы «Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр кертү хакында»гы 1-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законы, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законы, 2003 елның 12 маендагы «Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләре турында»гы 16-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы «Бәйрәкә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкә авыл җирлеге Башкарма комитеты карар итте:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Бәйрәкә авыл җирлеге башкарма комитетының 2012 елның 2 ноябрендәге 23 санлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Бәйрәкә авыл җирлеге гражданнарының һәм юридик затларның мөрәҗәгатьләрен карау буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын гамәлдән чыккан дип санарга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Бәйрәкә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча бастырып чыгару һәм Татарстан Республикасының Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасының Бердәм муниципаль берәмлекләре Порталы составында «Рәсми Татарстан» дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының Бердәм Порталы составында «Интернет»

мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://jaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Бәйрәкә авыл җирлеге башлыгы А.О.Әхмәтшина